КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1226

«Түбән Кама муниципаль районындагы «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә кушу рәвешендә «Түбән Кама муниципаль районындагы «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» һәм «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Түбән Кама муниципаль районындагы «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен (алга таба – «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге) «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районын-

дагы «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә (алга таба – «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) кушу рәвешендә, «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге эшчәнлегенең төп максатларын «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге эшчәнлегенең төп максатларына өстәп, 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Тукай урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәген һәм 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Кайманов урамы, 16 нчы А йорт адресы буенча урнашкан «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәген үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге базасында гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеген төзергә.

3. «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәген гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

эш көннәрендә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле булган, законнар белән каралган чараларны тәэмин итәргә;

«Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге эшчәнлеге туктатылу турында язу Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән вакыттан алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәгенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәтне алга таба файдалану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тәкъдимнәр кертергә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру чараларын үткәрү чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары өлешендә каралган акча чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, бу карарның 4 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәгенә элегрәк беркетелгән

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә тапшыруны тәэмин итәргә.

6. «Милосердие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү өлешендә каралган акча чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин